**М.Р.Саттарова**

КФУ, Казан

## Кием-салым атамаларының дини үзенчәлекләре

Халкыбызның дөньяны кабул итү, аңлауга бәйле үзенчәлекләрен өйрәнү бүгенге глобальләшү заманының мөһим бурычларыннан санала. Әлеге мәкалә кысаларында кием-салым атамаларына лингвокультурология фәне күзлегеннән тасвирлама бирү шул юнәлештә башкарыла торган эзләнүләрнең берсе. Көнкүрештә утилитар вазыйфа башкарудан тыш, кием-салым атамалары тотрыклы этник күрсәткеч буларак хезмәт итә, традицияләр, матди хәл, иҗтимагый үсеш турында мәгълүмат бирә. Халыкның милли киенү стиле, киемнәр комплексы элек-электән килгән этик, эстетик нормалар, икътисадый шартлар, башка этнослар белән багланышларга бәйле формалашкан.

Нинди кием-салым кию беренче чиратта халыкның георгафик шартларга яраклашуы белән бәйле. Татар халкы яшәгән җирләрдә табигать шартлары төрледән төрле булып, киемнәрне белдергән төшенчәләр дә күпсанлы. Мәкаләдә әлеге семантик төркемгә караган берәмлекләрнең Ислам дине белән бәйле булганнарын анализлау максаты куела.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә (2005) Ислам дине белән турыдан-туры бәйле булган кием-салым атамаларыннан түбәндәгеләр теркәлгән: *ахирәт күлмәге, бөркәнчек, ихрам, кәфен, пәрәнҗә, хиҗап, чадра, ябынча, җөббә*. Әлеге төшенчәләрне функциональ эчтәлекләренә карап ике төркемгә берләштерергә мөмкин. Беренчесе – көндәлек тормышта кулланыла торганнары: *бөркәнчек, пәрәнҗә, хиҗап, чадра, ябынча, җөббә*; ислам дине ритуаллары белән бәйлеләре – *ахирәт күлмәге, ихрам, кәфен*.

Сайлап алынган лексик берәмлекләрнең этимологиясе турында түбәндәге мәгълүматларны китерергә мөмкин: “Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге”ндә бу сүзләрнең берсе дә теркәлмәгән һәм шәрехләнмәгән. Шулай да әлеге кием-салым атамаларына аңлатма бирү мөмкин. *Ахирәт күлмәге* – беренче кат кәфен; *ахирәт* – үлгәннән соң булачак “теге дөнья” дип аңлатыла

[ТТАС 2005: 56]. Ахирәт сүзе гарәп теленнән кабул ителгән, дини тәгълимат буенча, кешенең җаны тәненнән аерыла (кеше үлә) һәм җан “икенче, теге дөньяда” яшәвен дәвам итә, Кыямәт көненнән соң ахирәт тормышы башлана. Күлмәк сүзе бүгенге татар телендә актив кулланылышта, гомумән алганда хатын-кызлар һәм ир-атлар кия торган өс киемен аңлата, килеп чыгышы белән гомумтөрки “кӧлмәк”, “кӧңләк” берәмлеге белән бәйле [ДТС 1969: 315; Әхмәтьянов 2001: 128].

*Бөркәнчек* – 1) электә хатын-кызлар йөзләрен яшерү өчен кием өстеннән башларына каплап куя торган җиңсез махсус япанча [ТТАС 2005: 106]. Килеп чыгышы белән борынгы төрки “бӧрк” – бүрек, каплавыч, шапка мәгънәсендә кулланылган сүз белән бәйле [Әхмәтьянов 2001: 56; ДТС 1969: 132].

*Ихрам* – 3) хаҗга баручыларның изге җиргә керер алдыннан өсләренә кия торган япма, тән өреткеч кием [ТТАС 2005: 201]. Әлеге лексик берәмлек гарәп теленнән алынган, харам “тыелган” мәгънәсендә, ягъни, әлеге киемне киюче кеше билгеле бер гамәлләрдән тыела, шул гамәлләр тыелган территориядә Ислам диненең бер фарызын – хаҗ гамәлен үти, шул халәттә була, ихрам кия.

*Кәфен* – 1) үлгәч кешене төреп күмү өчен ак тукыма [ТТАС 2005: 317]. Әлеге сүз рус теленә “саван” дип тәрҗемә ителә, М.Фасмер сүзлегендә бу берәмлекнең борынгы рус телендә үк кулланылганлыгы, грек, гарәп телләреннән кабул ителгән булырга тиешлеге күрсәтелә. Гарәп телендәге sabanijjat Багдад янындагы Сабанда эшләнелә торган тукыманы белдерә. Рус телендәге “саван” күмгән вакытта мәеткә кидерә торган ак тукыма кыемне аңлата [Фасмер 2004: 542]. Аңлатмадан күренгәнчә, татар телендә “кәфен” сүзенең мәгънәсе төгәл, мәеткә кидерелә торган кием-тукымалар җыелмасын аңлата.

*Пәрәнҗә* – чит ир-ат күзеннән чәч, йөз һәм буй-сынны яшерергә киелә торган һәм йөз каплау өчен махсус ат кылыннан куе итеп ясалган челтәре булган озын, киң халат [ТТАС 2005: 437]. Этимологиясе белән сүз пәрәнҗә “фәрәнҗи, фараджийя” – гарәп телендәге иркен итеп тегелгән өске кием дигән мәгънәгә барып тоташа. Әлеге киемне гадәттә Урта Азия һәм якын Көнчыгыш

илләрендә яшәүче мөселман хатын-кызлары кигән. Күзләр турысындагы челтәре “чачван” (фарсы телендәге “чашм банд” күзләр өчен бәйләү, повязка) дип аталган. Татар халкында әлеге кием бик сирәк кулланылган, бүгенге көндә дә аны киючеләр юк дәрәҗәсендә.

*Хиҗап* – 1) йөзне каплап йөри торган пәрдә, пәрәнҗә [ТТАС 2005: 633]. Әлеге сүз гарәп теленнән кабул ителгән, бөркәнчек дигән мәгънәдә кулланыла. Ислам дине кануннары буенча, баштан алып аякка кадәр хатын-кызның тәнен каплау өчен киелә торган барлык киемнәр дә хиҗап дип атала. Әмма Ислам дине дәүләт күләмендә кабул ителмәгән илләрдә хиҗап дип гадәттә чәч, муен, колакларны капларлык итеп башка киелә торган яулык, шарф кына аңлашыла. Ислам кануннары буенча, хиҗап кию нигез кагыйдәләрнең берсе булып тора.

*Чадра* – мөселман хатын-кызлар өйдән чыкканда, йөзләрен ят ирләргә күрсәтмәс өчен, бары күзләрен генә ачык калдырып, баштанаяк ябына торган җиңел япма, бөркәнчек [ТТАС 2005: 645]. Бу лексик берәмлек татар теленә фапрсы теленнән кабул ителгән ( چادر – палатка), ак, зәңгәр яки кара төстәге җиңел япманы белдерә. Чадра өйдән чыкканда кием өстеннән киелә һәм хатын-кызның гәүдәсен баштан аякка кадәр каплый. Кием дини һәм мәдәни аспектлардан чыгып киелә. Пәрәнҗә кебек чадра да татар хатын-кызлары арасында таралыш тапмаган.

*Ябынча* – 1) бөркәнчек; 2) пәрәнҗә [ТТАС 2005: 724]. Ябынча лексик берәмлеге борынгы төрки телдән килә торган *яп-* тамырына барып тоташа булса кирәк [ДТС 1969: 235]. Ябу, каплау мәгънәсендә кулланылганлыгын сүзнең рус классик әдәбиятында, рус тeleненең тарихи, аңлатмалы сүзлекләрендә урын алган мәгънәләре дә раслый.

*Җөббә* – мөселманнарда тукымадан тегелгән ирләр өс киеме [ДТС 1969: 790]. Әлеге сүз чапан белән синоним буларак аңлашыла. Этимологиясенә килгәндә, бу лексик берәмлек гарәп телендә кулланыла, جبة – “джубба” киң җиңле өске кием дигәнне аңлата [АРС 1994: 105].

Килеп чыгышы ягыннан сүзләрнең күпчелеге гарәп-фарсы алынмалары булуы табигый. Ислам дине ритуаллары, бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре

белән татар халкы тормышына читтән кабул ителгән. Шул сәбәпле, аерым предметлар сирәк кулланылышка ия. Пәрәнҗә, чадра, хиҗаб, җөббә кебек киемнәр моңа мисал булып тора, алар татар халкында популяр түгел. Әмма Ислам диненең нигезен тәшкил иткән намаз, хаҗ кебек гамәлләрне, мәетләрне тиешле таләпләргә туры китереп соңгы юлга озату йолаларын үтәүдә кулланыла торган предмет атамалары күпләргә таныш.

Сайлап алынган лексик берәмлекләрнең татар халык мәкальләрендә теркәлүен өйрәнү дә кызыклы. Мәсәлән, Н.Исәнбәт тарафыннан тупланган татар халык мәкальләре арасында өйрәнелә торган лексик берәмлекләр тупланган түбәндәге мәкальләр бар [Исәнбәт 2010].

14096 *Кигән ыштанны кем күрә? Күшәгәне ил күрә* (күшәгә (кашага) – бөркәнчек, җилән; юктан баеган, хәлләнгән, дәрәҗәгә менгән кешенең тәкәбберләнүенә мисалдан).

Кәфен сүзе мәкальләрдә дә турыдан-туры үлем белән бәйле кулланылган:

19137 *Башсыз атка менәрбез, җиңсез күлмәк киярбез*. (Бу очракта башсыз ат – табут; җиңсез күлмәк – кәфенне белдерә, ди Н.Исәнбәт). Шул ук эчтәлекле мәкаль:

19467 *Әҗәлнең мендергән аты башсыз, кидергән күлмәге җиңсез*. (Башсыз ат – табут, кулларда күтәреп алып барылган. Җиңсез күлмәк – кәфен)

19207 *Күлмәк кигән үлми, кәфен кигән килми*.

19478 *Күлмәк кигән бер кайтыр, кәфен кигән кайтмас*.

19238 *Кәфенеңне үлгәнче хәстәрлә*.

19252 *Үләсемне белсәм, кәфенемне муеныма урап йөрер идем*.

19268 *Авырганнан элек кәфенеңне хәзерлә*.

19463 *Бер сажин җир, өч аршын кәфен*.

19476 *Кәфен – байдан, үлем – Ходайдан, кабер – зират башыннан, нигә үлмәскә?*

19491 *Унике аршын бүз, ике аршын кабер*. Бу мәкаль "үлгәч кием-салым да, җир дә кирәкми, бездән тия торганы шул, шул җитә" дигән мәгънәдә әйтелә,

бүз – кәфен мәгънәсендә кулланыла. Шул ук мәгънәдә: *Унике аршын бүз, өч аршын җир* (элекке җирсез игенчеләр ишарә белән дә әйткәннәр).

13558 *Ике рәт йәнәшә мунча керсәң, үлгәч, кәфенеңне буярсың*. Шул ук мәгънәдә: *Ике рәт рәттән мунча кергән кеше, үлгәч, кәфенен пычрата, ди*.

22670 *Акчасыз базар – кәфенсез мазар.* Яки: 23082 *Акчасыз базарга барганчы, кәфенсез гүргә кер*.

22810 *Кәфенне бушка өләшсәләр, үлә кал*. Бушка алырга яратучыга тәнкыйть итеп, ирония белән әйтелә. Шул ук мәгънәдә: *Бушлый кәфен бирсәләр, үләргә дә риза*.

23131 *Бездә акча бер букча*. Яки: *Бездә акча бер букча: үлсәң, кәфенең чорнарга җитәрлек*! Бездәге акчаны тавык та чүпләп бетермәс.

23724 *Кәфил булсаң, кәфенең ки* (кәфил булу – йөккә керү).

32477 *Нәфес кәфенсез калдыра*. Бөлдерә, кәфенлек тә акчасы калмый, теләсә кайда үлеп кала, дигәнне аңлата.

Ябынча берәмлеге дә мәкальләрдә туры мәгънәсендә теркәлгән.

5862 *Ябу астында ял калыр, ял калмаса, йон калыр* (бирedә мал – “хайван”, ябу – тирен катырганчы өстенә капланган ябынча мәгънәсендә).

14202 *Ябынча кадере яңгырда беленер* (ябынча – япанча, ямылчы, яңгырдан бөркәнчек, юл һәм почта йөртүчеләр киеме).

14203 *Яз япанчаңны, кыш азыгыңны (онытма!).*

14180 *Аяз көнгә карама, япанчаңны ала чык*. Шул ук мәгънәдә: *Аяз көнне япанча ал*.

14201 *Япанга чыксаң, япанча ал* (япан – дала).

Аңлатмалы сүзлектә *ябынча, япанча* бөркәнчек, пәрәнҗә төшенчәләре белән аңлатылса да, татар халык мәкальләрендә кулланылган очраклардан аның гадәти тормышта кулланыла, яңгырдан, җилдән саклану өчен киелә торган кием икәнлеге аңлашыла. Рус телендәге мәгънәсе дә моны раслый: япанча, епанча төрки телдән кабул ителгән, «плащ, бурка»ны белдерә, борынгыдан билгеле кием, «Игорь полкы турында җыр»да ук телгә алынган (12 гасыр). 16-17 гасырларда көндәлек тормышта алтын, ефәк белән бизәлгән һәм хәлле

катламга караган кешеләр генә кигән. Кыска, сукнодан ясалган накидка буларак Петр I тарафыннан армия киеме итеп кертелгән. 18 гасыр ахырыннан бу предмет «плащ» дип атала. Хатын-кыз киеме буларак та билгеле. Россиядә 18-19 гасырларда «епанечка» – җиңсез, билгә кадәр озынлыктагы, сарафан өстеннән киелә торган плащ кулланылышта булган [Андреева 1997: 169].

Татар халкында Ислам дине белән бәйле булган икем-салым атамалары күп түгел. Сүзлектә теркәлгән тугыз сүздән кәфен, ябынча берәмлекләре генә милли үзаңда тирән уелган һәм шул рәвешле халык авыз иҗатының иң тотрыклы төре мәкальләрдә теркәлгән.

Өйрәнелә торган кием атамаларының матур әдәбиятта теркәлүе дә үзенчәлекле. Алар нигездә Ислам дине белән бәйле текстларда яисә татар әдәбиятында дини реформа темасы актив күтәрелгән чорда иҗат ителгән әсәрләрдә кулланыла. Мәсәлән, “Элекке феодаль Гарәбстанда, Иран, Төркиядә, Бохарада хатын-кызлар хокукта бик нык кимсетелеп, хәрәм-сарайларда, койма артларында, *чапан-пәрәнҗәләр* астында яшәргә мәҗбүр ителгәннәр. Әйтик, авыл хатын-кызлары андый *чапан-пәрәнҗәләр* астында бикләп тотылмаган [Исәнбәт 2010: 196].

Хәер, шәһәр бакчасында, өстенә *җөббә*, башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка бәтинкә, авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкертне туктатып, җүри, “вәкарь вә мәһабәтен” бозар өчен: “Син курай уйный беләсеңме?” — дип сорыйсым килде (Тукай, Мәкаләи махсуса).

Киң кара җөббәсен киеп, йә кулларын артына куйган килеш, йә үзенең гәрәбә тәсбихын тартып, кешеләргә гаепләүле караш ташлый-ташлый, караңгы чырай белән авыл буйлап йөренә. ... “Кәҗәме, сыермы, әллә безнең мулла *җөббәсеме*?” – дип уйлады ул. ... Мулланың *җөббә* кесәсеннән гәрәбә тәсбихы асылынып тора (Нәҗәти Җомалы, Кукуруз арасында).

Биш-ун минут эчендә тәмам уянып бетеп: "Йа Рабби, кабер эчендәменме?!" – дип, бераз хәрәкәтләнеп, кулы белән *кәфенен* ачты да: "Аллага шөкер! Күмелмәгәнмен икән!" – диде (З. Бигиев, Зур гонаһлар).

Болар шулай елашып утырганда, Маһруй, авыр мәшәкатьләр чигә-чигә каберстаннан өйгә кайтып җитеп, җир астыннан чыккан җен кебек, ап-ак *кәфенгә* төренгән килеш, бикләнми калган ишектән әнкәсе һәм ире утырган бүлмәгә килеп керде (З. Бигиев, Зур гонаһлар).

Болар да, мәсәлән, мөселман голәмасына охшар өчен ак *җөббә*, фаразан, кигән булганнар бит! (Ф.Әмирхан, Фәтхулла хәзрәт).

Нәтиҗә ясап түбәндәге фикерләрне әйтергә мөмкин. Аңлатма бирүдә "дини" дип билгеләнмәүгә карамастан, татар халкының милли киеме, Ислам дине таләпләре белән аваздаш булып, ир-ат һәм хатын-кызның җәмгыятьтә үз-үзен тоту этикетын, сәламәтлеген саклау һәм матурлыкны пропагандалый. Бүгенге әдәби телебездә кулланылган дини лексиканың кием-салымнарны белдергән өлеше, бик аз булуга карамастан, татар халкы тормышының аерылгысыз предметларын белдерә һәм тәрбия, көндәлек тормыш, гореф-гадәтләрне гамәлгә ашыруда үз урынын алган. Әлеге мәкаләдә анализланган сүзләр Ислам динен кабул итүгә бәйле рәвештә татар халкы тормышына үтеп кергән, аның сөйләм телен, халыкның тормыш рәвешен, дөньяга карашын, милли үзенчәлекләрен яңа төсмерләр белән тагын да баеткан.

**Әдәбият**

1. Андреева Р.П. Энциклопедия моды. – СПб.:. Литера, 1997. – 416 с.

2. Арабско-русский словарь. В 2-х т. Т. 1.– Ташкент: Камалак, 1994. – 456 с.

3. Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан, Татар.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

4. Древнетюркский словарь. – Ленинград, Наука, 1969. – 676 с.

5. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш.ред.: Ф.А.Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

7. Фасмер М. Этимологический словарь русского языка. В 4-х т. Т.3: Муза-Сят / М.Фасмер; Пер.с нем. и доп. О.Н.Трубачева.– 4-е изд., стер. – М.: ООО “Изд-во Астель”: ООО “Изд-во АСТ”, 2004. – 830 с.

## Названия одежды в татарском языке: религиозная специфика

**Резюме.** В настоящей статье анализируется религиозная специфика названий одежды, зафиксированные в толковом словаре современного татарского языка. Для наиболее полного раскрытия содержания изучаемого материала использованы этимологические данные отобранных единиц и их вербализация в татарских паремиях.